# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында

<u>1 статья.</u> 1994 елның 1 февраленнән хезмәт өчен түләүнең минималь күләмен 30 000 сум дип билгеләргә.

Хезмәт әчен түләүнең минималь күләменә өстәмәләр һәм өстәлмәләр, шулай ук премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре керми.

<u>2 статья.</u> Татарстан Республикасында гамәлдә булган салымнар турындагы законнар нигезендә хезмәт өчен түлеүнең минималь күләменә бәйле рәвештә салына торган салымнар, җыемнар,башка түләүләр 1993 елның 1 декабреннән 1994 елның 31 гыйнварена кадәр хезмәт өчен түләүнең 14620 сум итеп билгеләнгән минималь күләменнән чыгып, ә 1994 елның 1 февраленнән әлеге Законның 1 статьясында билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән чыгып исәпләнелә.

<u>3 статья.</u> 1993 елның 20 октябрендәге "Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында" Татарстан Республикасы Законы 1993 елның 30 ноябреннән көчен югалткан дип танырга.

<u>4 статья.</u> Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 8 феврале
N 2064-XII